| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 01.12.2017 | Казан ш. | № 6-184/тп |

Тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең куәт бирәмлегенә хисаплап, «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен 2018 елга түләү билгеләү турында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү системаларына тоташтыру тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 16 апрелендәге 307 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) хисаплап чыгару буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Техник тоташтыру мөмкинлеге булганда мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган объектының җылылык йөкләнеше сәгатенә 1,5 Гкал артып киткән очракта, тоташтырылга торган җылылык йөкләнешенең куәт бирәмлегеннән хисаплап, «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыруга (технологик ялгауга), шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, түләү билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 6-184/тп карарына кушымта

## Техник тоташтыру мөмкинлеге булганда мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган объектының җылылык йөкләнеше сәгатенә 1,5 Гкал артып киткән очракта, тоташтырылга торган җылылык йөкләнешенең куәт берәмлегеннән хисаплап, «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыруга (технологик ялгауга) түләү

мең сум/Гкал/сәг

| № п/п | Аталышы | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләрнең объектларын тоташтыру чараларын үткәрүгә чыгымнар ($П_1$) | 1,655 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең техник тоташтыру мөмкинлеге булганда тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 1,5 Гкал/сәг артып китүче объектларын тоташтыру ноктаpar кадәр җылылык челтәрләре ясауга (үзгәртеп коруга) (җылылык пунктлары төзүдән (үзгәртеп корудан) тыш) чыгымнар, ($П_{2.1}$), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир өсте) салу | |
| 2.1.1 | 50-250 мм | - |
| 2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2 | Җир астыннан салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал белән салу | |
| 2.2.1.1 | 50-250 мм | 1 961,720 |
| 2.2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2.2 | каналсыз итеп салу | |
| 2.2.2.1 | 50-250 мм | 1 991,987 |
| 2.2.2.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең техник тоташтыру мөмкинлеге булганда тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 1,5 Гкал/сәг артып китүче объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктлары төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар ($П_{2.2}$) | - |
| 4 | Табышка салым | - |